| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

22.04.2019 №343

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү исемлеген раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2018 елның 2 ноябрендәге 01-51/6619 номерлы хатын үтәү йөзеннән

КАРАР БИРӘМ:

1. Түбәндәгеләрне расларга:

1.1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының Татарстан Республикасы КФҮ ДБУ Нурлат филиалында күрсәтелүче дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеген (1 нче кушымта);

1.2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан КФҮләрдә комплекслы запрос ярдәмендә күрсәтелмәүче дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеге (2 нче кушымта).

1.3. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

1.4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеген раслау турында» 2017 елның 16 июнендәге 541 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Нурлатмуниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесенә йөкләргә.

Җитәкче Л.Н. Маняпов

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының

2019 ел, 22 апрель, 343 нче

карары белән расланган 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының Татарстан Республикасы КФУ ДБУ Нурлат филиалында күрсәтелүче дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеге**

| | |
|---|---|
| 1. | Торак бинаны үзгәртеп кору һәм (яки) үзгәртеп планлаштыруны килештерү (килештермәү) турында карар кабул итү |
| 2. | Бинаны торак бина, торак бина яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану |
| 3. | Торак (торак булмаган) бинаны торак булмаган (торак) бинага күчерү (күчерүдән баш тарту) турында хәбәр бирү |
| 4. | Төзелешкә рөхсәт бирү |
| 5. | Индивидуаль торак төзелеше объекты яки бакча йорты параметрлары белән билгеләнгән параметрларга һәм индивидуаль торак төзелеше объекты яки җир кишәрлегендә бакча йорты урнаштыруның рөхсәт ителүе (рөхсәт ителмәве) турында белдерүдә күрсәтелгән хәбәрнамәгә туры килү (туры килмәү) турында хәбәрнамә җибәрү |
| 6. | Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү |
| 7. | Индивидуаль торак төзелеше яки бакча йортының төзелгән яки үзгәртеп корылган объектларның шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килүе (туры килмәве) турында хәбәрнамә җибәрү |
| 8. | Рөхсәт ителгән төзелеш, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү |
| 9. | Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын әзерләү һәм бирү |
| 10. | Инженерлык челтәрләре һәм коммуникацияләр трассалары схемасын килештерү |
| 11. | Зыян күрүче гражданнарны Реестрга кертү |
| 12. | Ана (гаилә) капиталы акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган индивидуаль торак төзелеше объектын төзү (реконструкцияләү) буенча төп эшләр башкаруны раслаучы документ бирү |
| 13. | Җир кишәрлеген шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалануга рөхсәт бирү турында карар кабул итү |
| 14. | Җирлекнең (шәһәр округының) генераль планыннан өземтә бирү |
| 15. | Шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасында тотылучы белешмәләр бирү |
| 16. | Җир эшләре башкаруга ордер (рөхсәт) бирү |
| 17. | Адресларны бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару |
| 18. | Белешмә бирү (өземтә) |

| | |
|---|---|
| 19. | Агач һәм куакларны кисәргә, кыскартырга, төпләргә рөхсәт бирү |
| 20. | Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү |
| 21. | Җир кишәрлеген яки җир кишәрлекләрен территорияләрнең кадастр планында урнаштыру схемасын раслау |
| 22. | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген даими (срогы чикләнмәгән) файдалануга бирү |
| 23. | Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген милеккә бушлай бирү |
| 24. | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген түләүсез файдалануга бирү |
| 25. | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген сатулар үткәрмичә сату |
| 26. | Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген сату үткәрмичә арендага бирү |
| 27. | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген җир кишәрлегендә урнашкан биналар, корылмалар милекчеләренә милеккә яисә арендага бирү |
| 28. | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген аукцион формасында үткәрелә торган торгларда арендага бирү |
| 29. | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген аукцион формасында үткәрелә торган торгларда сату юлы белән милеккә бирү |
| 30. | Муниципаль милектә булган җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм шәхси милектә булган җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү |
| 31. | Муниципаль милектә булган җирләрне яки җир кишәрлеген куллануга рөхсәт бирү |
| 32. | Аерым максатларда ачык сервитут урнаштыру |
| 33. | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген гражданнарга һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына эшчәнлекләрен гамәлгә ашыру өчен милек итеп (арендага) бирү |
| 34. | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген торак пункт чикләрендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен гражданнар милкенә (арендага) бирү |
| 35. | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген гражданнарга бакчачылык алып бару өчен милеккә (арендага) бирү |
| 36. | Шәхси яки муниципаль милектәге җир кишәрлеген бер категориядән (авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән тыш) башка категориягә күчерү турында карар кабул итү |
| 37. | Җир кишәрлегеннән даими (срогы чикләнмәгән) файдалану хокукын яки җир кишәрлегеннән гомерлек мирас итеп файдалану хокукын туктату турында карар кабул итү |
| 38. | Җир кишәрлеген сатып алу турында карар кабул итү |
| 39. | Җир кишәрлеген арендалау шартнамәсенә үзгәрешләр кертү |
| 40. | Җир кишәрлекләрен бушлай бирү хокукына ия затлар буларак исәпкә кую |
| 41. | Муниципаль милектәге җир кишәрлегенә карата сервитут билгеләү турында килешү төзү |
| 42. | Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген гражданнарга шәхси торак төзелеше өчен милеккә (арендага) бирү |

| | |
|---|---|
| 43. | Муниципаль торак фондының торак урыннарын гражданнар милкенә тапшырганда документлар рәсмиләштерү |
| 44. | Элек хосусыйлаштырылган торак урыннарны муниципаль милеккә кабул итү |
| 45. | Муниципаль учреждениеләргә, муниципаль казна предприятиеләренә оператив идарә хокукында һәм муниципаль унитар предприятиеләргә хуҗалык алып бару хокукында муниципаль милекне рәсмиләштерү (беркетү) |
| 46. | Муниципаль милек реестрыннан өземтә бирү |
| 47. | Муниципаль милектә булган һәм арендага бирү өчен билгеләнгән күчемсез милек объектлары турында мәгълүмат бирү |
| 48. | Муниципаль казнадан кергән мөлкәтне арендага тапшыру |
| 49. | Муниципаль милек реестрына керә торган муниципаль милекне арендага бирү |
| 50. | Муниципаль берәмлек мөлкәтен сатуларны үткәрмичә түләүсез файдалануга тапшыру |
| 51. | Шартнамә төзү хокукына торглар нәтиҗәләре буенча муниципаль милектән түләүсез файдалану шартнамәсен төзү |
| 52. | Муниципаль милекне арендалауның гамәлдәге килешүенең өзелүе |
| 53. | Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү |
| 54. | Муниципаль милектәге урнашкан су объектын яки аның бер өлешен файдалануга бирү турында рөхсәт бирү |
| 55. | Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә, индивидуаль эшкуарларга, физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләрдән тыш) субсидияләр бирү (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш) |
| 56. | Ваклап сату базарын оештыру хокукына рөхсәт бирү |
| 57. | Муниципаль берәмлек чикләрендә тулысынча яки өлешчә җирле әһәмияттәге юллар буйлап уза торган маршрутлар буенча авыр йөкләрне, зур габаритлы йөкләрне автомобильләрдә күчерү өчен рөхсәт бирү |
| 58. | Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан файдаланучыларга автомобиль юлларының торышы турында мәгълүмат бирү |
| 59. | Муниципаль преференцияләр бирү |
| 60. | Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына муниципаль милекне биләү һәм (яисә) файдалануга тапшыру |
| 61. | Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу |
| 62. | Муниципаль торак фондында гражданнарга хезмәт торак урынын найм шартнамәләре буенча торак урыннары бирү |
| 63. | Социаль наем шартнамәсе буенча бирелгән муниципаль торак фондыннан торак урыннарын алыштыру буенча документларны рәсмиләштерү |
| 64. | Муниципаль торак фондыннан гражданнарга социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирү |
| 65. | Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар исәбенә кую |

| | |
|---|---|
| 66. | Авыл җирендә яшәүче гражданнарга, шул исәптән яшь гаиләләргә һәм яшь белгечләргә торак төзү (сатып алу) өчен социаль түләүләр бирү |
| 67. | «2014-2020 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасы буенча торак сатып алу (төзү) хокукы турында исәпкә кую һәм таныклык бирү |
| 68. | Архив белешмәләре, архив өземтәләре, архив документлары күчермәләре бирү |
| 69. | Дәүләт милкенә кертелгән һәм муниципаль архивта саклanучы архив фондлары буенча архив белешмәләре, архив өземтәләре, архив документлары күчермәләре бирү |
| 70. | Тууны дәүләт теркәве |
| 71. | Никах төзүне дәүләт теркәве |
| 72. | Аерылышуны дәүләт теркәве |
| 73. | Уллыкка (кызлыкка) алуны дәүләт теркәве |
| 74. | Ата булуны билгеләүне дәүләт теркәвенә алу |
| 75. | Исемне үзгәртүне дәүләт теркәвенә алу |
| 76. | Үлемне дәүләт теркәве |
| 77. | Граждан хәле актлары язмасына төзәтмәләр яисә үзгәрешләр кертү |
| 78. | Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында кабаттан таныклыклар һәм гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу фактын раслаучы башка документлар (белешмәләр) бирү |
| 79. | Гражданлык хәле актлары язмаларын торгызу (гамәлдән чыгару) |

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының

2019ел, 22апрель, 343нче

карары белән расланган 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан КФҮләрдә комплекслы запрос ярдәмендә күрсәтелми торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеге**

| | |
|---|---|
| 1. | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген аукцион формасында үткәрелә торган торгларда арендага бирү |
| 2. | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген аукцион формасында үткәрелә торган торгларда сату юлы белән милеккә бирү |
| 3. | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген крестьян (фермер) хуҗалыгы тарафыннан аның эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен гражданнарга һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына милек итеп бирү (арендага) |
| 4. | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген торак пункт чикләрендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен гражданнар милкенә (арендага) бирү |
| 5. | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген гражданнарга бакчачылык алып бару өчен милеккә (арендага) бирү |
| 6. | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген гражданнарга бакчачылык алып бару өчен милеккә (арендага) бирү |
| 7. | Муниципаль милек реестрына керә торган муниципаль милекне арендага бирү |
| 8. | Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар исәбенә кую |
| 9. | Авыл җирендә яшәүче гражданнарга, шул исәптән яшь гаиләләргә һәм яшь белгечләргә торак төзү (сатып алу) өчен социаль түләүләр бирү |
| 10. | «2014-2020 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасы буенча торак сатып алу (төзү) хокукы турында исәпкә кую һәм таныклык бирү |